СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан,
Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы,
ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы,
Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п.,
Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru,
www.saby.tatarstan.ru

№ 37 от 15.12.2025

на № _______ от _______________

КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Советының 2024 елның 27 июнендә
269 нчы номерлы карары белән расланган
Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районында муниципаль хезмәт турында
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2025 нче елның 3 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кануны кабул ителүгә бәйле рәвештә, Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» 2024 елның 27 июнендә 269 номерлы Саба муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.1 пунктта «которое» сүзен «который» сүзенә алмаштырырга;

1.2. 3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Муниципаль хезмәт вазифаларын биләү өчен түбәндәге квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу - вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфалардан тыш; авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яисә урта һөнәри белем булу;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек буенча стаж, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.»;

1.3 23.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23.3. Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органын юкка чыгарганда, аның шәхси эше юкка чыгарылган җирле үзидарә органы функцияләре тапшырылган җирле үзидарә органына яисә аның хокукый варисына саклауга тапшырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча халыкка җиткерергә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов